# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

**17 ноябрь, 2025 ел** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге Әсән Елга авылында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге Әсән Елга авылында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

2026 елда Кукмара муниципаль районының Пычак авыл җирлеге Әсән-Елга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

урам яктырту;

су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

коеларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү;

яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;

янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын урнаштыру, ремонтлау;

һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаганнары) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү;

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау;

традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау;

каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын төзү, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Пычак авыл җирлеге башлыгы Г.Ш. Нәфыйков

ОГРН 1021607752979
ИНН 1623001928